**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2677**
**02.05.2024**

Башкарма комитетның 2024 елның 26 гыйнварындагы 475 номерлы Карары белән расланган шәһәр элемтәсендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2024 елның 26 гыйнварындагы 475 номерлы Карары белән расланган шәһәр элемтәсендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 42 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42. Субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече булып юридик зат, шәхси эшмәкәр керемнәрендә кайтарылган югалтуларның Тарифлар буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты тарафыннан расланган 100 тапкыр һәм аннан күбрәк юл йөрүгә озак вакытлы файдаланудагы билет белән түләгәндә бер тапкыр йөрү һәм бер урын багаж алып баруның максималь чик тарифы буенча алынган керем (ташламалы, балалар өчен ташламалы транспорт карталарын тулыландырудан алынган керемне исәпкә алып) суммасына нисбәте тора (алга таба - нәтиҗәлелек күрсәткече).».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 2 маендагы
2677 номерлы карарына
кушымта

Шәһәр элемтәсендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү буенча _____ елның «____» __________ № ____ шартнамәгә кушымта

Субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында
хисап

| Т/с | Субсидия алучының исеме | Нәтиҗәлелек күрсәткеченең исеме | План буенча нәтиҗәлелек күрсәткеченең зурлыгы | Хисап датасына нәтиҗәлелекнең факттагы күрсәткече | Транзакцияләрнең гомуми саны (берәмлек) | Алынган субсидия (сумнарда) | Кайтарылган югалтулар % | Субсидиядән файдалану юнәлеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

Кушымта: раслаучы документларның күчермәләре.
Вәкаләтле затның
вазыйфасы имза имзаның расшифровкасы
Башкаручы ___________________ ______________ _________________________
(имза) (вазыйфа) (имзаның расшифровкасы)

М.У.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева